ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяга түбәндәге эчтәлекле $15^1$ пункт өстәргә:
“$15^1$) региональ әһәмияттәге автомобиль юлларының иминлеген тәэмин итүгә региональ дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;”;

2) 13 статьяга түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
“$1^1$) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының иминлеген тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;”;

3) 28 статьяның 1 өлешенә “авыр йөкле транспорт чарасы хәрәкәте” сүзләреннән соң “, корал белән үзйөрешле транспорт чаралары, Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең корал, хәрби техника һәм хәрби мөлкәт ташуны гамәлгә ашыручы хәрби техника, транспорт чаралары хәрәкәтеннән тыш,” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 7 мае
№ 31-ТРЗ